**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» марта 2019 год №5

«Аккүз авыл мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе
Уставын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Аккүз авыл мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең Уставын (алга таба - «Аккүз авыл мәдәният йорты» МБУ) яңа редакциядә(кушымта итеп бирелә) расларга.
2. «Аккүз авыл мәдәният йорты» МБУ директорын, «Аккүз авыл мәдәният йорты» МБУ Уставын теркәгәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче районара салым инспекциясендә яңа редакциядә һәм башка үзгәрешләр кертергә, гаризаны, башка документларны имзаларга, кирәкле гамәлләрне һәм формальлекләрне башкарырга вәкаләт бирергә.
3. Әлеге карар “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыккан көненнән түбәндәге адрес буенча:http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Аккүз авыл җирлеге бүлегендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Аккүз авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.А.Сәлихҗанов